**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

18.07.2020 № 223

**Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проекты турында**

Җирле үзидарәне үстерү буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Совет утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 30 гыйнварындагы Пр-354 номерлы йөкләмәләре исемлегенең 3 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, алар карамагындагы оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг уздырылганда һәм аларны эшкәрткәндә мәгълүмати технологияләрдән файдалануны камилләштерү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын (алга таба – ТИҮ проекты) гамәлгә ашыру буенча проект офисын булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә ТИҮ проекты кураторы функцияләрен йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, кара-каршы элемтәнең цифрлы платформасын куллануны да кертеп, ТИҮ проектын гамәлгә ашыру өчен нигез мәгълүмат системасы булып тора дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилгә ТИҮ проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы рәисе булырга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

ТИҮ проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисын булдырырга һәм проект офисы рәистәше сыйфатында Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгын билгеләп, аның составын расларга;

ТИҮ проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы турындагы нигезләмәне, шулай ук аны гамәлгә ашыруда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлек регламентын расларга;

Иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча «Диалог» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек турындагы килешүдә катнашучы якларның берсе булырга;

әлеге боерыкны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

6. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына Иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча «Диалог» автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек турындагы килешүдә катнашучы якларның берсе булырга.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**